СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2020 елның 3 июне № 45/12

Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 29 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районына керүче «Алешкин-Саплык авыл җирлеге», «Зур Аксу авыл җирлеге», «Зур Чынлы авыл җирлеге», «Городище авыл җирлеге», «Звезда авыл җирлеге», «Кече Чынлы авыл җирлеге», «Марс авыл җирлеге», «Матак авыл җирлеге», «Түбән Чәке авыл җирлеге», «Яңа Борындык авыл җирлеге», «Яңа Әлмәле авыл җирлеге», «Яңа Ишле авыл җирлеге», «Үби авыл җирлеге», «Иске Чүпрәле авыл җирлеге», «Иске Кәкерле авыл җирлеге», «Иске Чокалы авыл җирлеге», «Иске Шәйморза авыл җирлеге» «Чуаш Чүпрәлесе авыл җирлеге», «Шланга авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре Советларының әлеге җирлекләр Советларына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрне тапшыру турында тәкъдимнәрен кабул итәргә:

җирлекнең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау, җирлекнең генераль планнары нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру буенча документларны раслау, җирлекләрне шәһәр төзелеше проектларының җирле нормативларын раслау.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советына, төзеләчәк торган килешүләрнең гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагылуын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының югарыда күрсәтелгән авыл җирлекләре советлары белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында, бюджет законнары нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына Татарстан

Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын эшләргә һәм карап тикшерүгә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы урынбасары А.Е. Ярухинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль<br>районы башлыгы, Татарстан Республикасы<br>Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе: М.Р. Гафаров